РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ НЫРЬИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НЫРЬЯ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

Нырья авылы

06 февраль, 2024 ел № 4

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 10 өлешендәге 3 пункты нигезендә Нырья авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторларының кушымта итеп бирелгән исемлеген расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы В.И. Павлов

Нырья авыл җирлеге Советының 06.02.2024 елның 4 карарына 1 нче кушымта

**Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1. Җирле үзидарә органына реклама элмә тактасын килештерү турында гариза җибәрү факты булмаганда, автомобиль транспортын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча контрольдә тотыла торган зат тарафыннан эшчәнлек башланган көннән алып 90 календарь көн узу.
2. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, квартал дәвамында объектларны һәм төзекләндерү элементларын җыештыру буенча эшләрне башкару бурычы йөкләнгән оешма хезмәткәрләре санының, әлеге эшләрне башкару өчен билгеләнгән җыештыру һәм махсус техника санының шул ук вакыт аралыгында артуы булмаган очракта, 50 һәм аннан да күбрәк процентка кимүе (ләкин ким дигәндә ике хезмәткәр).
3. Хезмәт күрсәтү территориясендә ике календарь атна дәвамында объектларны һәм төзекләндерү элементларын җыештыру буенча эшләрне башкаруны үз бурычларына керткән оешмага хезмәт күрсәтү территориясендә травматологик ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән гражданнар санының, алдагы шул ук чор белән чагыштырганда, 15 һәм аннан да күбрәк процентка артуы.
4. 30 календарь көн эчендә таләпләре Муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән контроль объектының торышыннан тайпылуның өч һәм аннан да күбрәк шундый ук очраклары ачыклануы турында гражданнардан, оешмалардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан кергән, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән һәм (яки) килгән мәгълүматларның дөреслеген бәяләүгә юнәлдерелгән чаралар нәтиҗәсендә алынган төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре һәм закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы турында сөйли торган мәгълүмат булу.
5. Контрольдә тотылган затка карата чыгарылган төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозган өчен административ җәза билгеләү турында административ хокук бозу турында эш буенча бер ел эчендә кимендә биш карар булу.
6.Торак пунктның бер административ-территориаль берәмлеге (урам, микрорайон) территориясендә ике календарь атна дәвамында травма алуга бәйле рәвештә травматологик ярдәм күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән гражданнар санының, алдагы шул ук чор белән чагыштырганда, 15 һәм аннан да күбрәк процентка артуы.